# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегең Поршур авылында 2026 елда гражданнарның үзара салымын керту турында

25 ноябрь 2025 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплар турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,( статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 2 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьяс нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авь җирлегенең Поршур авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Югары Чура авь җирлегенең Поршур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һ балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буен укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм анн өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәр хезмәткә чакырылган затлардан; махсус хәрби операциядә катнашучы хәр хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үза салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмиятт мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм баш подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һ электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашы өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- урамнарны яктырту җайланмасы;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манаралары скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, а чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган баш инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территория төзекләндерү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төз ремонтлау;

- мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр)булмага һәйкәлләрне төзү, ремонтлау

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомоби юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- тротуарларны төзү, ремонтлау;

- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру;

торак пункт чикләрендә җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, гомум файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торга җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;

- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуна калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Югары Чура авыл җирлегенең мәгълүмат стендларын Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре портал составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan. урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокук актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Чура авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары: Афанасьев А.Н